**Сабантуй-2017.**

Иң элек мәйдан әзерләнә. Ике бала белән тәрбияче: Әйдәгез, сабантуйга”- дигән сүзләр белән мәйданга чакырып йөриләр.

**Җыр “Сабантуе - хезмәт туе.”**

**Балалар :**

1 шатлыклар күңелебездә

Ак кояш күгебездә

Килегез дуслар кунакка

Сабантуи бүген бездә.

**2 бала**

Җилферди чиккән сөлгеләр

Бүләкләр күбебезгә

Корәшик тә, узышыйк та

Сабантуй бүген бездә.

**3 бала**

Әйдәгез бер рәхәтләнеп

Шаярыгыз, көлегез,

Рәхәтләнеп көлә белү

Витамин ул белегез.

Көлегез, көлегез,

Файдасы күп белегез.

А.Б: Ә хәзер сезнең каршыгызда безнең 10 төркем малайлары бию биеп күрсәтерләр.

**Татар халык биюе малайлар.**

А.Б: Бәйрәм бүген бәйрәм бүген

Бар донья көлеп тора

Сабан туй бәйрәмнәре

Һәр җирдә гөрләп тора.

Даниял Салимов башкаруында **“Зәңгәр күл” шигырен** тыңлап китегез”

А.Б. Безнең бүгенге бәйрәмебезне тагын да ямьләндерергә кечкенә кызыбыз , Нуретдинова Ассель килгән. Әйдәгез бергәләп алкышлап каршы алыйк.

**Җыр “Сандугач - күгәрчен”( Ассель башкаруында)**

А.б.  Кадерле балалар хөрмәтле кунаклар,хәерле көн. Бүген без татар халкының олы бәйрәме – сабан туена җыелдык. Сабантуй – ул хезмәт бәйрәме,дуслык бәйрәме. Котлы булсын сабантуйлары.

**(Музыкага Камырша белән Батырша керәләр).**

Камырша :Минем арттан йөрмә диеп әйттем бит инде.

Батырша :Кем - кем артыннан йөри бит әле.

А.б Туктагыз әле, сез кемнәр буласыз... нигә тарткалышасыз..бүген бездә СабантуЙ,иң яхшысы үзегез белән таныштырыгыз.

Бергә: Исәнмесез балалар ,исәнмесез кунаклар,

Камырша:Алайса таныш булыйк. Бу минем игезәк сыңарым –Батырша. Котыгыз алынмасын, үзе бик әйбәт ул.

Батырша:Ә бу минем җан дустым Камырша . Камырша без дә сабантуй карыйк әле.

А.б. Карап кына утырмагыз әле. Менә сезгә бау. Аркан тартышыгыз.

Бергә:Була ул!(икесе аркан тартышалар).

А.Б.Балалар әллә сез дә булышасызмы?

*Уен аркан тартышу (Зурлар төркеме чыга.)*

Батырша :ә хәзер безнең биисе килә.

А.б Сабантуи елга бер килә

Күңелле олы бәйрәм

Нур өстенә нурлар иңсен

Биеп алыйк ичмасам

**Татар халык биюе (барысы бергә)**

**Шүрәле керә.**

Ш.Кем тавыш күтәрде, нинди биюләр, җырлар монда. Ай яй кеше күп монда. Кая әле кети кети уйнап алыйк әле.

**Уен "Кытыклау**".

Ш.Үзегез бәйрәм итәсез, ә мине чакырмагансыз. Былтыр да монда икән.

Батырша: Монда шул. Ә син нәрсә эшләп килдең монда, бәйрәмне бозарга дип уйлыйсың ахрысы.

Ш: Юк юк, минем дә уйныйсым килә

А.б. Сабантуй уеннарын дәвам итәбез,  алайса  мә Шүрәле син дә катнаш.

Кашыкка салып күкәйне

Йөгерегез тизрәк

Күрик әле бу ярышта

Кайсыгыз җитезрәк.

**Уен "Кашыкка күкәй салып йөгерү"**

(уртанчылар төркеме чыга)

Камырша:менә сиңа сулы чиләк

Көянтә ал иңеңә

Йөгер тизрәк, иң алдан кил

Егыла гына күрмә.

**Уен "Су ташу" ( 2 кечкенәләр төркеме чыга)**

Батырша :

Чүлмәк ватам, чүлмәк ватам

Ватып булырмы икән

Бүләккә бер чиккән яулык

Алып булырмы икән.

**Уен "Чүлмәк вату". (мәктәпкә әзерлек төркеме)**

Камырша белән Батыршаның көрәшәселәре килә.

Камырша: яле көрәшик. Хәзер мин сине егып салам Батырша.

**Көрәш бара. (мәктәпкә әзерлек төркеме)**

Сабантуйның батырын билгеләп алыйк әле.

А.б Менә дуслар көтеп алган сабан туйлары да тәмам. Тагын бер елга сау бул Сабан туе барыгызга да саулык сәламәтлек телим. Киләсе елга да сабан туйларында очрашырга язсын саубылыгыз дуслар.